| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2017 Казан ш. № 8-2/соц

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә сатыла торган азык-төлеккә (товарларга) өстәмә бәяләрнең чик дәрәҗә максималь күләмнәрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 07 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә сатыла торган азык-төлеккә (товарларга) өстәмә бәяләрнең чик дәрәҗә максималь күләмнәрен билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасының башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләрендә җәмәгать туклануы предприятиеләрендә сатыла торган азык-төлеккә (товарларга) чик дәрәҗә максималь бәя күләмнәрен билгеләү турында» 11.10.2012 № 8-1/соц карарының көчен югалтуын танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
03.11.2017 № 8-2/соц карарына кушымта

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә сатыла торган азык-төлеккә (товарларга) өстәмә бәяләрнең чик дәрәҗә максималь күләмнәре

| № п/п | Мәгариф оешмасының тибы | Өстәмә бәянең чик дәрәҗә максималь күләме, процент | |
|---|---|---|---|
| | | Шәхси җитештерүдәге продукцияне әзерләү өчен кулланыла торган чималга | Сатып алына торган товарларга (кулинариядә эшкәртмичә) |
| 1 | Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары | 70,0 | 30,0 |

Искәрмә:

1. Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләрендә сатыла торган азык-төлеккә (товарларга) шушы карарда билгеләнгән өстәмә бәяләрнең чик дәрәҗә максималь күләмнәре, оешу-хокук рәвешенә, милекчелек рәвешенә бәйсез рәвештә, барлык җәмәгать туклануы предприятиеләре тарафыннан, шулай ук юридик зат төземичә үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы барлык шәхси эшкуарлар тарафыннан кулланыла.

2. Шәхси җитештерүдәге продукциягә Россия Федерациясенең ГОСТ 31985-2013 «Җәмәгать туклануы хезмәтләре. Терминнар һәм билгеләмәләр» илкүләм стандартында каралган ысуллар белән кулинариядә эшкәртү узган, ризык рәвешендә комплектланган чимал керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге